УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Об установлении карантина на территории деревни Малалла Кайбицкого района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с выявлением заболевания бешенством животных и угрозой его распространения в населенных пунктах Республики Татарстан, в соответствии со статьями 3^1, 17 Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Установить карантин в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных на территории деревни Малалла Кайбицкого района Республики Татарстан.

2. На территории, указанной в пункте 1 настоящего Указа, в период действия карантина запрещаются:

торговля домашними животными, их вывоз за пределы соответствующей территории и отлов (для вывоза в зоопарки, с целью расселения в других районах) диких животных;

убой на мясо животных, больных или подозрительных по заболеванию бешенством;

реализация, использование в пищу и для скармливания животным молока от животных, больных бешенством;

реализация, использование в пищу и для скармливания животным молока от клинически здоровых животных без пастеризации в установленном порядке;

вывоз за пределы соответствующей территории шерсти, шкур, полученных от клинически здоровых животных и не прошедших дезинфекцию в установленном порядке.

3. Установить, что карантин подлежит отмене по истечении двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством при условии выполнения необходимых мероприятий.

4. Главному управлению ветеринарии Кабинета Министров Республики Татарстан разработать и утвердить план мероприятий по ликвидации бешенства животных на территории, указанной в пункте 1 настоящего Указа, а также обеспечить его реализацию.

5. Контроль за исполнением настоящего Указа возложить на Кабинет Министров Республики Татарстан.

6. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

Президент
Республики Татарстан **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
22 мая 2017 года
№ УП-424

УКАЗ
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
УКАЗЫ

Татарстан Республикасы Кайбыч районының Малалла авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында

Терлекләрнең котыру авырулы булуы ачыклану һәм аның Татарстан Республикасы торак пунктларында таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының 3^1, 17 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кайбыч районының Малалла авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертергә.

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә карантин гамәле дәвам иткән вакытта түбәндәгеләр тыела:

йорт хайваннарын сату, аларны әлеге территориядән читкә чыгару һәм кыргый җәнлекләр (аларны зоопаркларга чыгару, башка районнарда үрчетү максатларында) тоту;

котыру авырулы яисә авыру дигән шик тудыра торган хайваннарны ит өчен сую;

котыру авырулы терлекләрнең сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә пастеризацияләнмәгән сөтен сату, ризыкка куллану һәм хайваннарга ашату;

клиник сәламәт терлекләрнең билгеләнгән тәртиптә дезинфекцияләнмәгән йонын, тиресен әлеге территориядән чыгару.

3. Карантин, зарури чаралар күрү шарты үтәлгәндә, терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагы көненнән ике ай вакыт узгач бетерелергә тиеш, дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территориядә терлекләрнең котыру белән чирләвен бетерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга, шулай ук аның гамәлгә ашырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге Указның үтәлешенә контрольне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына йөкләргә.

6. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 22 май
№ ПУ-424